**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Яңа Саклау торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2023 нче елның 17 нче ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Яңа Саклау авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Яңа Саклау авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; хәрби хезмәт үтүчеләрдән; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, , яшәү урыны буенча Яңа Саклау авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өсен түбәндәге эшләрне башкарырга җибәрергә:

1) традицион күмү урыннарын төзекләндерү (койма тоту)

3. Әлеге карарны Саклаубаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина